КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 25 декабрь г.Казань № 1202

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коррупциягә каршы бизнес» иҗтимагый процедуралар үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 26 июль, 598 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Коррупциягә каршы бизнес» иҗтимагый процедуралар үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2018 ел, 26 июль, 598 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «2015 – 2020 елларга» сүзләрен «2015 – 2022 елларга» сүзләренә алыштырырга;

әлеге карар белән расланган «Коррупциягә каршы бизнес» иҗтимагый процедуралар үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибендә:

2 нче пунктта «2015 – 2020 елларга» сүзләрен «2015 – 2022 елларга» сүзләренә алыштырырга;

5 нче пунктның дүртенче абзацында «банкротлык» сүзен «аңа карата банкротлык процедурасы гамәлгә кертелмәсә, Үзәкнең эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмаса» сүзләренә алыштырырга;

6 нчы пунктның сигезенче абзацында «банкротлык» сүзен «аңа карата банкротлык процедурасы гамәлгә кертелмәве, Үзәкнең эшчәнлеге Россия Федерациясе законнары белән күздә тотылган тәртиптә туктатылмавы» сүзләренә алыштырырга;

9 нчы пунктның өченче абзацында «Үзәк тарафыннан тапшырылган мәгълүмат» сүзләрен «Үзәк тарафыннан тапшырылган документлардагы мәгълүмат» сүзләренә алыштырырга;

12 нче пунктта «субсидиядән файдалану турындагы хисапларны тапшыру вакытлары һәм формалары» сүзләрен «субсидия бирү нәтиҗәсе, субсидиядән файдалану турындагы, шул исәптән аны бирү нәтиҗәсенә ирешү турындагы хисапларны бирү тәртибе, вакытлары һәм формасы, Министрлыкның Үзәк тарафыннан өстәмә хисаплар бирү вакытларын һәм формаларын билгеләү хокукы» сүзләренә алыштырырга;

түбәндәге эчтәлекле $12^1$ нче пункт өстәргә:

«$12^1$. Үзәк тарафыннан эшчәнлекне Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2015 – 2022 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» дәүләт программасын раслау турында» 2014 ел, 19 июль, 512 нче карары белән расланган «2015 – 2022 елларга Татарстан Республикасында коррупциягә каршы сәясәт тормышка ашыру» дәүләт программасына теркәлгән кушымтаның 7.7 нче пункты белән билгеләнгән вакыт эчендә гамәлгә ашыру субсидия бирүнең нәтиҗәсе булып тора.»;

14 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«14. Үзәк квартал саен, хисап кварталыннан соң килүче айның 15енә кадәр, Министрлыкка кушымтада күрсәтелгән форма буенча субсидиядән файдалану турында, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында хисап кертә.»;

Тәртипкә кушымта (карарга теркәлә) өстәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

«Коррупциягә каршы бизнес» иҗтимагый процедуралар үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасына Татарстан Республикасы бюджетыннан субсидия бирү тәртибенә кушымта

Форма

«Коррупциягә каршы бизнес» иҗтимагый процедуралар үзәге» коммерциягә карамаган автоном оешмасының
20___ елның _________ хәленә карата субсидиядән файдалану турында,
шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү турында
хисап

(сум)

| Т/с | Субсидия бирү нәтиҗәсенә ирешү | Субсидияне тоту юнәлеше | Бирелгән субсидиянең күләме | Хисап чоры башына субсидиянең калган өлеше | Хисап чорында касса чыгымнары | Касса чыгымнарын раслый торган документларның исеме, реквизитлары (номеры һәм датасы) | Хисап чоры ахырына субсидиянең файдаланылмый калган өлеше |
|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | | | |
| | | | | | | | |

Җитәкче ________________________________ ___________ ____________________________________________________
(вазыйфасы) (имзасы) (Ф.И.Ат.ис.)

Баш бухгалтер _____________________________________________________ __________ ________________
(Ф.И.Ат.ис.) (имзасы) (телефоны)

20___ ел, «___» _______________

_______________________________________